ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04 июль 2025 ел

№ 4907

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучылар һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен өстәмә социаль ярдәм чаралары турында» 2025 елның 23 гыйнварындагы 361 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар ризык белән тукландыруны оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны кайнар ризык белән туклandыруның уртача бәясен раслау турында» 2024 елның 12 сентябрендәге 777 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 21 апрелендәге 253 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучылар һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен өстәмә социаль ярдәм чаралары турында» 2025 елның 23 гыйнварындагы 361 номерлы Карарына (Башкарма комитетың 2025 елның 9 июнендәге 4118 номерлы Карары редакциясендә), 1, 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«1. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның түбәндәге категорияләре өчен бер тапкыр түләүсез кайнар ризык билгеләргә:

1) 1-4 сыйныф укучылары өчен: бер укучыга түләүсез туклану бәясе – 74,77 сум;

2) балигъ булмаган 3 һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдә тәрбияләнүче 5-11 сыйныф укучылары өчен бер укучыга түләүсез туклану бәясе – 88,70 сум.

2. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның түбәндәге категорияләре өчен ике тапкыр түләүсез кайнар ризык билгеләргә:

1) инвалид балалар, сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле балалар өчен: бер укучыга туклану бәясе 1-4 сыйныфлар өчен – 128,90 сум; 5-11 сыйныфлар өчен – 130,88 сум;

2) Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе хезмәткәрләренең, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенең федераль дәүләт граждан хезмәткәрләренең, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсендә эшләүчеләрнең балалары өчен: бер укучыга туклану бәясе 1-4 сыйныфлар өчен – 128,90 сум; 5-11 сыйныфлар өчен – 130,88 сум;

3) «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Россия МГГ ВТСИ» ФДКУ филиалы – Яр Чаллы шәһәре буенча ведомстводан тыш сак бүлеге хезмәткәрләренең, граждан персоналының балалары өчен: бер укучыга туклану бәясе 1-4 сыйныфлар өчен – 128,90 сум; 5-11 сыйныфлар өчен – 130,88 сум;

4) Донецк һәм Луганск халык республикаларыннан, Херсон һәм Запорожье өлкәләреннән, Украинадан килгән, вакытлыча Яр Чаллы шәһәрендә урнаштырылган күчеп китәргә мәҗбүр булучыларның балалары өчен: бер укучыга туклану бәясе 1-4 сыйныфлар өчен – 128,90 сум; 5-11 сыйныфлар өчен – 130,88 сум;

5) махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балалары өчен: бер укучыга туклану бәясе 1-4 сыйныфлар өчен – 128,90 сум; 5-11 сыйныфлар өчен – 130,88 сум;

6) махсус хәрби операциядә катнашканда яралану сәбәпле дәваланууда булган гражданнарның балалары өчен: бер укучыга туклану бәясе 1-4 сыйныфлар өчен – 128,90 сум; 5-11 сыйныфлар өчен – 130,88 сум;

7) махсус хәрби операциядә катнашу чорында алган авыру аркасында яки хәрби травма аркасында инвалид булган гражданнарның балалары өчен: бер укучыга туклану бәясе 1-4 сыйныфлар өчен – 128,90 сум; 5-11 сыйныфлар өчен – 130,88 сум;

8) махсус хәрби операция зонасында һәлак булган яки хәбәрсез югалган гражданнарның балалары өчен: бер укучыга туклану бәясе 1-4 сыйныфлар өчен – 128,90 сум; 5-11 сыйныфлар өчен – 130,88 сум.».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов